ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

14.08.2020 № 389-р

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 сентябрендәге 416-р номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 30.09.2015 ел, № 416-р боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.2 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга.

6.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6.7. Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр күренеп торган һәм өстәмә тикшерү таләп итмәгән очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгать итүгә җавап телдән шәхси кабул итү барышында бирелергә мөмкин, бу хакта гражданны шәхси кабул итү карточкасында язу теркәлә. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә".

6.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Телефоннар буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән срокларда теркәлергә тиеш. Телефоннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен кабул итүгә вәкаләтле органның вазыйфаи заты гражданның мөрәҗәгатен терки һәм, контактлы телефонын һәм (яисә) электрон почта адресын (алар булса) күрсәтеп, мөрәҗәгать итү карточкасын формалаштыра. Мөрәҗәгать карточкасындагы белешмәләр тиешле органнарга җибәрелә, алар компетенциясенә әйләнештә куелган мәсьәләләрне хәл итү керә.

2. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А.Газизуллин